**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылышы уналтынчы утырышы**

**КАРАРЫ**

**08 август 2022 ел** **№ 54** **Айдар авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
Айдар авыл җирлеге Советының 04.10.2017 ел, № 75
«Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә
әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны
«Интернет» челтәрендәге Теләче муниципаль районының рәсми
сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм
мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе
турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенеңаерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2002 ел, № 90-ФЗ Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы прокурорының 30.06.2002 ел, № 02-08-01-2022 протестын караганнан соң, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» челтәрендә Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2017 елның 04 октябрендәге 75 номерлы карары белән расланган: «г) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешен, пайларны), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акча чыганаклары турында белешмәләр, әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең, аның хатыны (иренең) алыш-биреш кылуга алдагы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Айдар авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хаҗиев